**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«НАРАТЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**XXXXXVI СЕССИЯ**

**КАРАР № 2**

Наратлы авылы 20.05.2019 г.

**Наратлы авыл җирлеге Советының**
**2019 елның 14 февралендә булып узган**
**XXXXXIV сессиясендә кабул ителгән**
**“Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы**
**“Наратлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә**
**гавами тыңлаулар (җәмәгать тикшерүе)**
**оештыру һәм үткәрү тәртибе турында”гы**
**Нигезләмәне раслау хакында”гы 1нче карарга**
**үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**Наратлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАР БИРДЕ:**

Наратлы авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 февралендә булып узган XXXXXIV сессиясендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Наратлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать тикшерүе) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында”гы Нигезләмәне раслау хакында”гы 4нче карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 4нче бүлектә:

- *4нче пунктны яңа басмада бәян итәргә:*

«4. Гавами тыңлаулар халык, Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авыл җирлеге Советы, Бөгелмә муниципаль районы “Наратлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы (“Наратлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла.

Халык, Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авыл җирлеге Советы инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Наратлы авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә “Наратлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы (“Наратлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла торганы “Наратлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Наратлы авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **С.А. Дмитриев**